| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 3 апрель г.Казань № 260

Паллиатив медицина ярдәме системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 24 гыйнварындагы 34 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Паллиатив медицина ярдәме системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарның гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 3 апрель, 260 нчы
карары белән расланды

Паллиатив медицина ярдәме системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип паллиатив медицина ярдәме системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Паллиатив медицина ярдәме системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга кадәр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән расланган «2021 елга кадәр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла, анда паллиатив медицина ярдәме системасын үстерү чаралары һәм федераль бюджеттан күрсәтелгән чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидияләр була.

3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын төп бүлүче булып Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тора.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Татарстан Республикасы бюджетының паллиатив медицина ярдәмен үстерүгә бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүгә акча җибәрә:

а) дару препаратлары белән тәэмин итү, шул исәптән авыртуны басар өчен;

б) паллиатив медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларын, медицина эшләнмәләре белән тәэмин итү, шул исәптән өйдә куллану өчен.

5. Акчаларны тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсендә ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләме һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан финансланунының иң чик күләмнәрен җиткергәннән соң расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә финанслауның чик күләмнәрен җиткерә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә паллиатив медицина ярдәме системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыру максатларында дару препаратлары һәм медицина әйберләре сатып алуга дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт контрактларын (шартнамәләрен) төзи;

дәүләт контрактлары (шартнамәләре) шартлары нигезендә паллиатив медицина ярдәме системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыру максатларында дару препаратлары һәм медицина әйберләре сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләре) төзелгән оешмаларга акча күчерә.

8. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы паллиатив медицина ярдәме системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итүгә кергән акчаларның максатчан кулланылышын тикшереп торуны тәэмин итәләр.

9. Акчаларны максатсыз файдалану Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

10. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына квартал саен, хисап чоры тәмамланганнан соң 25 календарь көннән дә соңга калмыйча һәм ел саен, киләсе елның 2 апреленнән дә соңга калмыйча Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча, әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган чараларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшыра.

11. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләнә.

12. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган акчалар Россия Федерациясе Бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.